| СОВЕТ ЛЕБЯЖИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЯЖЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.02.2022 с. Лебяжье № 27

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсен, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсен һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсен гамәлгә ашыру максатларында

**Лебяжье авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» Нигезләмәне, кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы һәм үзара салым акчаларыннан файдалану турында Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 8 октябрендәге 130 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
4. Әлеге карарны веб-адрес буенча Алексеевск муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://alekseevskiy.tatarstan.ru урнаштырырга һәм веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебяжье авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Д.Ә.Гыйләҗев**